СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423181, РТ, Новошешминский район,
село Тубылгы Тау, ул.Молодежная, д.73,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423181,ТР, Яңа Чишмә районы,
Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы,
73

тел.:(8-84348)3-82-58,факс:(8-84348)3-82-44,Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

№ 21-71

2022 елның 16 нчы июне

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының саны һәм урнашу урыннары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының санын һәм урнашу урыннарын расларга, кушымта нигезендә;

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 21.04.2002 ел, №19-65 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) рәсми чыганаклары турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмагилов

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгытау авыл җирлеге
Советының 2022 елның 16 нчы июне
21-71 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының саны һәм урнашу урыннары

Урнашу урыны	Норматив-хокукый акт урнаштыру өчен форма атамасы	Саны, шт.
ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр ур., 73	Махсус мәгълүмат стенды	1